Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 16**

Күки авылы 2017 елның 27 сентябре

Күки авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләмен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Күки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2016 елның 8 сентябрендәге 15 номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авылҗирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында”гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башлыгының акчалата бүләкләүне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2016 елның 06 октябрендәге 18 номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” гы карары белән расланган Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын;

2. Билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең акчалата бүләкләү һәм вазыйфаи окладлары күләмен, шулай ук айлык өстәмәләр һәм түләүләр күләме күтәрелгәндә (индексацияләгәндә) бер сумга кадәр артырга тиеш

әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау җирле бюджетта тиешле финанс елына каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.3.Копию настоящего решения направить в Финансово-бюджетную палату Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 нче йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов